ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**05.06.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1210**

Рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында

Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Зур Завод урамы, 39А йорты адресы буенча урнашкан, 16:49:011304:11 кадастр номерлы җир кишәрлеге өчен рөхсәт ителгән төзелеш параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турындагы Әхмәрова А.Я. мөрәҗәгатен карап чыгып, 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы РФ Шәһәр төзелеше кодексы, «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре нигезендә, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Кишәрлек чикләреннән торак йортка кадәр көнбатыш ягыннан минималь чигенүләрне 3 метрдан 1 метрга кадәр киметү өлешендә, Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Зур Завод урамы, 39А йорты адресы буенча урнашкан, 16:49:011304:11 кадастр номерлы җир кишәрлеге өчен рөхсәт ителгән төзелеш параметрларыннан читкә тайпылуга А.Я. Әхмәровага рөхсәт бирергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников